КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 февраль г.Казань № 43

Татарстан Республикасы Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Казан - Оренбург» автомобиль юлын һәм М-7 автомобиль юлын тоташтыручы «Сорочьи Горы - Шәле» автомобиль юлын төзү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[I] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба - Баштатюлтранс) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Казан - Оренбург» автомобиль юлын һәм М-7 автомобиль юлын тоташтыручы «Сорочьи Горы - Шәле» автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Татар Янтыгы авыл җирлеге адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясеннән 16:24:040201:24 кадастр номерлы 11 029 079 кв.метр мәйданлы «ТФБ-Рент инвестиция фонды» ябык рента пай инвестиция фонды (алга таба - җир кишәрлеге милекчесе) милкендәге җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 5 124 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба - алына торган җир кишәрлеге) алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән 16:24:040201:24 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 5 124 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген урнаштыруның беркетелгән схемасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырырга;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны бастырып чыгарырга;

әлеге карарның күчермәләрен Баштатюлтранска, җир кишәрлеге милекчесенә, «Росреестрның федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалына җибәрергә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң, Баштатдортранс белән берлектә, Татарстан Республикасы Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында Килешү (алга таба – килешү) әзерләү һәм аның җир кишәрлеге хуҗасына җибәрү өчен 30 көнлек срок эчендә;

килешү төзергә;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләргә;

җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәве;

җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан закон белән билгеләнгән срокта кул куелган килешү тапшырылмаган очракта судка тиешле дәгъвалар бирергә.

4. Баштатюлтранска әлеге карарның 2 пункты белән расланган 16:24:040201:24 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 5 124 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген урнаштыру схемасы нигезендә җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләре үткәрүне тәэмин итәргә.


2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 1 февраль, 43 нче карары белән расланды

16:24:040201:24 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 35 124 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасы

| Җир кишәрлегенең шартлы номеры – :21:ЗУ1 | | |
|---|---|---|
| Җир кишәрлегенең мәйданы - 5 124 кв.метр. | | |
| Координатлар системасы – МСК-16 | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координатлар, метр | |
| | X | У |
| н1 | 453668.10 | 1343067.00 |
| н2 | 453698.60 | 1343092.40 |
| н3 | 453700.41 | 1343094.39 |
| н4 | 453557.71 | 1343141.46 |
| н5 | 453558.90 | 1343138.80 |
| н6 | 453567.80 | 1343126.10 |
| н7 | 453585.60 | 1343105.10 |
| н8 | 453614.20 | 1343067.00 |
| н9 | 453624.30 | 1343061.30 |
| н10 | 453642.70 | 1343055.60 |
| н11 | 453661.20 | 1343060.70 |
| н1 | 453668.10 | 1343067.00 |




Масштабы 1:2 000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 16:24:040201:24 | – чыганак җир кишәрлегенең кадастр саны; |
| :24:ЗУ1 | – барлыкка килә торган җир кишәрлеге билгесе; |
| (red line) | – барлыкка килә торган җир кишәрлеге чикләре билгесе; |
| (black line) | – җир кишәрлекләре чикләре билгесе; |
| (blue line) | – кадастр кварталы чикләре билгесе; |
| (light blue line) | – территориядән файдаланунын махсус шартлары булган зона билгесе; |
| 16:24:040201 | – кадастр кварталы билгесе; |
| н1 | – урнашу урынын билгеләү өчен мәгълүматлары җитәрлек булган чикнең характерлы ноктасы билгесе. |